# ЯШЬЛӘР ХӘЯТЫННАН БЕР ЛӘҮХӘ[1]

Икенде[2] вакыты иде.

Баерга якынлашкан кояшның нуры төшеп су өстләре кызыл-сары төскә кергән; һавада бертөрле салкынлык таралып, бөтен табигатьтә тынлык вә сөкүнәтә мәел[3] башланган иде.

Шул вакыт «Кавказ һәм Меркурий» ширкәтенең Астраханьнан килә торган «...» исемле пароходы Казан пристанена килеп туктады. Пароход юлчылар белән тулы иде. Юлга такта салыну белән, халык бик ашыгып вә берен-бере этәреп чыга вә кайсылары керә башладылар. Күп юлчыларның якыннары каршы алырга төшкән иде. Анлар, шатлык илә күрешеп вә үбешеп, һәркем үз юлына юнәлергә тотынды. Пароходтан төшкән юлчылар эчендә Сәлим әфәнде дә бар иде.

Ул, татар интеллигенты диикме, яшьләрдән берәү диикме, — ни дисәк тә, татар мәдрәсәләрендә күп еллар ятканнан соң русчага вә дөньяви гыйлемгә бирелгән вә бер заманнар «халык хезмәте» өчен дә көч сарыф иткән бер әфәнде иде. Яше егерме дүртләрдә, буйга-башка чамалы, йөреш-торыш вә киемдә садә[4], шуның илә бәрабәр фәгъгаль димаглы[5], үткен нәзарлы[6] вә гали рухлыдыр. Ул пароходка Самарадан утырган, Казанга килүе тору өчен түгел, бәлки вакытлы бер эш белән генә иде.

Сәлим пароходтан чыгып трамвайга утырды да Печән базарына[1+] килде. Әүвәл килүләрендә төшкән бер татар номерына килеп бүлмә сорады. Тар вә караңгырак бер бүлмә бирделәр. Ул, бүлмәгә кереп, нәрсәләрен куеп та бетмәгән иде, керле алъяпкыч бәйләгән татар плавое[7] килеп, бик нәзакәтсез[8] рәвештә аның паспортын алып китте.

Сәлим, мәгыйшәтнең томанлы вә караңгы бер җиреннән килгәнгә, заманның гыймран вә сәнаигы нәфисәсе[9] илә зиннәтләнгән Казанны гизәргә ашыга иде, — алдырып чәй генә эчте дә вакыт качырмыйча шәһәрне гизү өчен урамга чыкты. «Көфер почмагы»[2+] тирәсеннән, кайнап торган мөэминнәр[10] яныннан үтеп Болакның[3+] аргы ягындагы урамнарга таба китте, һава гүзәл вә ләтыйф[11] булып, күк йөзе ачык, ай вә йолдызлар үзләренең

---

[1]*Ләүхә* — күренеш.

[2]*Икенде* — кояш баер алдыннан укыла торган намаз.

[3]*Сөкүнәтә мәел* — хәрәкәтсезлеккә, тынлыкка авышу.

[4]*Садә* – гади.

[5]*Фәгъгаль димаглы* — эшчән зиһенле.

[6]*Нәзарлы*— карашлы.

[7]*Плавое — половой* — гостиница хезмәтчесе.

[8]*Нәзакәтсез* — тупас, дорфа.

[9]*Гыймран вә сәнаигы нәфисәсе* — төзелеш һәм нәфис сәнгате.

[10]*Мөэминнәр* — мөселманнар — бу урында мөселманлыкны саклау пәрдәсе астында искелек белән «сәүдә итүчеләр».

[11]*Ләтыйф* — йомшак.

тонык вә салкын нурларын яна гына агыза башлаганнар иде. Табигатьнең һәрбер уңгаеннан истифадә кылырга[1] гадәтләнгән мәдәни халык һаваның бу ләтафәтен ганимәт белеп[2] урамга чыкканнар. Проломный вә Воскресенский урамнары[4+] халык белән тулган иде. Урамның фәүкыльгадә[3] якты вә тәмиз[4] булуы, ике ягын каплаган мәһабәт вә гүзәл гыймран вә анда йөргән халыкның сурәт вә кыяфәте аның дикъкатен җәлеп итте. Ул Урта Азиядән килә иде. Зиһененә андагы шәһәрләрнең вә халыкларның сурәт вә кыяфәте килеп, ике мәдәният вә ике мәгыйшәт арасында булган фәрекъ[5] аның күз алдында тәҗәссем иткән[6] кеби булды. Яңа мәдәният кул астына керүе кичегә төшкән Бохараи шәриф[5+] белән күптән үк мәдәни куәт тәэсирендә яшәгән Казан арасындагы зур аерма аның шәрекълеккәнәфрәтен китерде. Ирләр белән бер сафта ук ачык йөз белән йөреп, табигатьнең ләтафәтеннән истифадә кылган хатыннарны күреп, гыйлемнең сәмәрәсенә тәхсин итте[7].

Бу урамнарда татар бик аз иде. Хосусән,калпаклылар бармак белә генә санарлык иде. Сәлим үз танышларыннан берничәсен очратып, адресларын алыштылар, Воскресенский урамының шәрекъкә таба башына килгәч, биек, мәһабәт вә шәүкәтле[8] улан ак бинаның башындагы «Императорский университет»[6+] дигән садә вывесканы күреп, бөтен дикъкате шуңа юнәлде. Сәлимнең һичкемгә игътираф кылмаган[9] вә рухының иң төбендә яшеренеп, яткан «университетка керү» дәрте бар иде. Ул, үзенең яшьтә өлкәнлегенә вә хәзерлексезлегенә карамыйча, бервакыт шул университетка шәкерт булуны бик чынлап өмид итә иде. Югарыдагы вывеска астындагы мәһабәт ак бина аңарга ят бер тәэсир бирде. Шул бина эчендә үзенең булачак бер өмиде вә бер сәгадәте сакланган кеби булып, беркадәрле заманнардан соң шул бина эчендәге өмиденә ирешәчәген уйлап, күңелендә бер шатлык әсәре сизде.

Урамнан үтеп барган яки университетка кереп-чыгып йөргән бер студентны күрү аның гыйбта[10] хисен уйгата, шуның кеби хокукка малик[11] булса, мәсгуд[12] булыр төсле була иде.

Ул тәбган бик мөтәэссир вә мөтәхассас[13] кеше иде. Үзенең өмиде белән

---

[1]*Истифадә кылырга* — файдаланырга.
[2]*Ганимәт белеп* — бәхеткә санап.
[3]*Фәукыльгадә* — гадәттән тыш.
[4]*Тәмиз* — чиста, пакь.
[5]*Фәрекъ* — аерма.
[6]*Тәҗәссем иткән* — гәүдәләнгән.
[7]*Сәмәрәсенә тәхсин итте* — нәтиҗәсен яхшы дип тапты.
[8]*Шәүкәтле* — бөеклек.
[9]*Игътираф кылмаган* — белдермәгән.
[10]*Гыйбта* — кызыгу.
[11]*Малик* — ия.
[12]*Мәсгуд* — бәхетле.
[13]*Тәбган бик мөтәэссир вә мөтәхәссас* — табигате белән үк тәэсирләнүчән һәм тойгыга бирелүчән, нечкә хисле.

галякасы[1] улан садә бинаны ташлап китә алмыйча, төрле уйлар белән аның дүрт ягыннан акрын-акрын әйләнде. Зиһене шунда кереп уку, соңра аның сәмәрәсе[2] улан «гүзәл тормыш»ны уйлау белән мәшгуль иде.

Төрле уйлар, хыяллар вә мазый вә истикъбальдән[3] төрле ләүхәләр зиһененнән кичкәннән соң, авыр вә басынкы адымнар белән номерына юнәлде. Юлда, үзенең кыйммәт вә кайтарылмый торган яшь гомере вә иҗтиһады[4] үз каршында һич кирәге булмаган бер юлга түгелүене тәфәккер итеп, рухан аглады[5].

Бунлар аны шул дәрәҗә җиңгән иде ки, ул номер ишеге төбенә кайтып җиткәнен сизми дә калды. Номерның баскычларын авыр вә салмак атлап керде дә пальтосын салып, университетны күрү өмиде илә тәрәзәдән тыш якка күз салды. Вакыйган, аның рәсадханәсе[6] илә түбәләре күренә иде. Бунлар аның рухын үзләренә тарткан кеби булдылар. Әллә нинди бер дәрт вә бер хөббеннәфес[7] илә аның агызыннан шул сүзләр чыкты:

— Сакалым агарыр, билем бөкрәер, ләкин мин, сау булсам, шул бинага бервакыт әгъза булырмын...

**II**

Сәлим моннан элек Казанга ике мәртәбә килгән, инде бусы өченче килүе иде. Шул өч килүендә Казан аңарга өч төрле тәэсир итте, бер-беренә мохалиф улан[8] өч төрле хиссият бирде.

Бу тәэсир, бу ихсасларның[9] алышынуы вә төрләнүе Казанның үзгәрүеннән түгел, бәлки Сәлимнең үзенең үзгәрүеннән иде.

Ул Казанга һәр килүендә үзенең идея — гаяи хыялия[10], игътикад вә әхвале рухиясе[11] җәһәтеннән бик зур инкыйлабларга мөсадиф иде[12]. Иң әүвәлге килүе 1901 нче елда булып, ул бу вакыт бик саф вә халис[13] милләтче иде. Хиссияте миллиясенең[14] иң куәтле вә иң ялкынлы бер дәвере булып, милләт тәрәккыйсеннән[15] башканы уйламый вә бөтен шәхсиятен милләт өчен фида кыйлырга хәзер иде. Шундый ялкынлы милли идеяле яшь бер адәмгә, табигый, бер вакытлар татар ханлыгы хөкем сөргән вә соңгы заманнарда да

---

[1]*Галякасы* — бәйләнеше.
[2]*Сәмәрәсе* – нәтиҗәсе.
[3]*Мазый вә истикъбальдән* — үткән һәм киләчәктән.
[4]*Иҗтиһады*— тырышлыгы.
[5]*Тәфәккер итеп, рухан аглады* — уйлап, рухи яктан елады.
[6]*Рәсадханәсе* — күзәтү объекты.
[7]*Хөббеннәфес* — үзсүзлелек, мин-минлек.
[8]*Мохалиф улан* — охшашмаган.
[9]*Ихсасларның* — хисләрнең, тойгыларның.
[10]*Гаяи хыялия* — хыялдагы теләк.
[11]*Игътикад вә әхвале рухиясе* — ышану һәм эчке кичерешләре.
[12]*Инкыйлабларга мөсадиф иде* — үзгәрешләргә очрый иде.
[13]*Халис* — чын.
[14]*Хиссияте миллиясенең* — милли хисләренең.
[15]*Тәрәккыйсеннән* – алга китүеннән.

Идел буе татарлары тормышында бик зур роль уйнаган «Казан шәһәре» бик тирән милли хиссиятләр кузгатмыш иде. Шул хисе аны, номерга төшкәч чәй эчеп, алай-болай ипләнүгә, иң башлап «Хан мәсҗеде»н[7+] зиярәткә сәвекъ итмеш[1] иде.

Ул плавойдан анда барырга юлны өйрәнде дә тиз генә юнәлде. Аңарга ачу иткән кеби, сакчы: «Якшәмбедән башка көндә кертмимез», — дип маташса да, Сәлимне туктата алмады; ул ун тиенлекне төртте дә кереп китте. Әүвәлән мәсҗеднең янына барып, бик озак дикъкать белән карап торды. Кирпечләре кырылып беткән, тузган; үзе егылырга якын булган югары вә биек манара, бер яктан, татарның борынгы шәүкәтле, галиб[2] вә хаким булуын, ханлык заманнарын күз алдына китерсә дә, икенче яктан, авыр вә өмидсез тәэсир бирде. Заманның мәдәнияте белән вөҗүдкә килгән[3] гали биналар янында садә вә иске манараның торуыннан килгән мәнзарә[4] гүя хәл теле белән аңа әйткән кеби тоелды: «Инде татар картайды; аның дәвере үтте. Аның урынын яшь хәятлы икенчеләр алды... Бу табигый... менә мин татарның мәгълүбиятенең[5] мөҗәссәм һәйкәле, хәятының гәүдәле дәрәҗәсе... Мин ничек иске вә беткән булсам, татар да шуның кеби хәлсез вә беткәндер».

Соңра ишеген ачтырып, аның эченә керде. Никадәрле иске вә тузган исә дә, бу бина аңа сөйкемле кеби, үзенеке кеби тоела, шуңа әллә нинди бер якынлык хис кыйла иде. Озын вә уңгайсыз баскычларыннан, кыенлык белән булса да, манараның иң башынача менде. Хакыйкатән[6], бик биек иде. Казан кечкенә күренә,ерактагы вә шәһәрдән бөтенләй читтәге биналар якын күренәләр иде. Үзләренең шәүкәт вә галәбәле заманнарында салынган шул бинаның башыннан карауның аңа биргән хисләрен төяп, ул төште. Манарадан[8+] чыкты, Воскресенскийның шул башында торган Икенче Александрның[9+] мәһабәт вә газамәтле[7] һәйкәлен күреп, күңелендә хәсәд хисе уянды.

Соңра музейга керде. Анда да милли асаре гатикалар[8] бар иде. Анлар да аның хиссияте миллиясен кузгатты. Бунлар аны һәммәсе борчуга салган, милли шәүкәтнең инкыйразының[9] мөҗәссәм[10] мисаллары аны бик авыр тәфәккергә[11] чумдырган иде. Шунлардан котылу өчен ул, Печән базары

---

[1]*Зиярәткә сәвекъ итмеш* — барып күрергә юнәлгән.
[2]*Галиб* — өстен.
[3]*Вөҗүдкә килгән* — барлыкка килгән.
[4]*Мәнзарә* — күренеш.
[5]*Мәгълүбиятенең* — җиңелгәнлегенең.
[6]*Хакыйкатән* — чыннан да.
[7]*Газамәтле* — олы, мәһабәт.
[8]*Асаре гатикалар* — борынгы әйберләр.
[9]*Инкыйраз* — бетү, сүнү.
[10]*Мөҗәссам* – зур.
[11]*Тәфәккергә* – уйлауга.

ягына кайтып, көтепханәләргә керде, кыйраәтханәгә[1] барды. Бунда яңа-яңа әсәрләр, гәзитәләр, анларда милләтнең ихтияҗатенә гаид фикерләр, хыяллар вә төрле өмидләр бар иде. Анын эче җылынды, күңеле күтәрелеп, зиһененнән «тәрәккый итәмез бит» уе кичте. «Болгар» вә «Сарай» номерлары[10+] өстендәге «Азад»[11+] вә «Мөхбир»[12+] гәзитәләренең мәһабәт вывескалары аңа тагы җылы күренде.

Беренче килүендә Казанның үзенә тәэсирен уйгаткан хиссиятен тасвирга тырышып, Сәлим бер мәкалә язган иде. Вакытилә мәйданга чыкмаган бу мәкаләне, аның үзеннән рөхсәт белән, без бу урында дәреҗ итеп[2] китүне тиеш күрәмез. Тәкрар вә тәгъкыйдле[3] җөмләләрне үзгәртергә мәҗбүр булсак та, анын тәгъбиратын[4], фикерен мөмкин кадәрле бозмаска тырыштык. Ул менә шуннан гыйбарәт иде;

*«Милләт кайгысы яки Казан шәһәре*

Мөхтәрәм Казан! Минем өчен вә гомумән татар милләтенең тәрәккый вә сәгадәтен арзу кылган[5] һәркем өчен син милли нәзарда башка шәһәрләрдән артыксың; имтияз[6] вә ихтирамлы күренәсең... Сөйкемле вә якын тоеласың... Күңел сине сөя вә якын күрә, башка илләрдән алда саный. Чөнки: син бер заманнар безем милләтнең ма биһилифтихары[7], шан вә шәрәфе идең. Син безем бабаларымызны җиһангир[8] ясап, анларга шундый куәт вә шундый мәһабәт бирдең ки, дошманнар аларның исемен генә ишетсә дә, йөрәге тетри, куллары калтырый вә каушап хәлләре бетә иде.

Заманнар үтте. Хәлләр алышынды. Дәһернен мәсаибе[9], тәкъдирнең ачы көннәре ирешеп, син галәбә вә хакимиятеңне җуйдың; кол вә хәкыйрь[10] булып калдың. Әүвәлге шан вә шәрәфләр һәммәсе бетеп, безнең заманга фәкать шул: караганда күзләремездән яшь агыза торган манараң гына калды... Синең бу тәнәззелеңне[11], мәгаттәәссеф[12], игътираф итсәк[13] тә, синең һаман да башка илләрдән алда булганлыгыңны, татар тормышы комедиясендә син һаман иң мөһим роль уйнаганыңны инкяр мөмкин түгелдер.

---

[1]*Кыйраәтханә*— уку өе, бүлмәсе.
[2]*Дәреҗ итеп*— теркәп, арага кертеп.
[3]*Тәгъкыйдле*— аңлаешсыз, буталчык.
[4]*Тәгъбиратын* — мәгънәсен.
[5]*Арзу кылган* — теләгән.
[6]*Имтияз* — башкалардан аерылып тору,өстен булу.
[7]*Ма биһилифтихары* — мактанычы.
[8]*Җиһангир* — дөньяны үзенә каратучы, яулап алучы.
[9]*Дәһернең мәсаибе* — заманның кайгылары, бәлаләре.
[10]*Хәкыйрь* — түбән дәрәҗәле, кадерсез.
[11]*Тәнәззелеңне* — түбәнлегеңне.
[12]*Мәгаттәәссеф* — үкенечкә каршы.
[13]*Игътираф итсәк* – кимчелекләрен танысак.

Үзеңдә хөкем вә тәсаррыф[1] булмаса да, син башка илләр дәрәҗәсенә төшмәдең: татарлар өстендә каты вә караңгы сөкүнәт хөкем сөргән заманда син «гыйлем вә голәманың мәркәзе» идең, синдә уку бөек шәрәф санала; гыйльми мәсьәләләрдә сиңа мөрәҗәгать ителә иде. Дини вә милли ихтияҗатне дәфгыдә[2] син иң башлап кузгала идең; цензур Коръән вә хәдисне бастырмый, имеш, көчләп диннән чыгаралар, имеш, дигән хәбәрләр чыгу белән, син иң башлап Петербурга кеше җибәрдең, дингә кысулар була, имеш, хәбәрен ишетү белән синең халкыңның дин гайрәте һиҗрәткә[3] мәҗбүр итте; никах вә талак мәсьәләләре мәхкәмәгә[4] алына, имеш, дигән хәбәр сине тизүк бер-бер артлы прошениеләр яудыруга, милләт өчен ялынырга мәҗбүр итте.

Күп заманнардан бирле син үз милләттәшләреңгә милли бүрек, кәләпүш, читек, кәвеш, таз, комган хәзерләдең, киемнәр тегеп кидердең. Өстемезгә бик озак заманнар хөкем сөргән калын вә караңгы төн үтеп, таң якынлыгын белдерә торган галәмәтләр иң башлап синдә зоһур итте[5]. Схоластика белән миләре череп, гакыллары тәкълид[6] богавы илә богауланган, милләт микробы булудан башкага ярамаган голәма эченнән Шиһабетдин әл-Мәрҗани[13+] һәм Курсавиларның[14+] зоһурилә[7] син мөшәррәф булдың[8]; татар эчендә мисле сәбкать итмәгән[9] мөхтәрәм Каюм Насыйри[15+] кеби милләт хадимнәренең вөҗүденә син мәзъһәр[10] булдың. Татарда иң башлап син матбага ачтың[16+]. Иң әүвәлге көтепханәне син вөҗүдкә китердең[17+]. Шулай ук татарларның «уяныр вакытка» керүләрен белдергән галәмәтләрне иң элек син изһар кылдың[11]. Идел буе татарларында ысуле җәдидә[12] мәктәпләрен, мәктәп китапларын башлап син вөҗүдкә китердең. Носул җәдидче, тәкый гаҗәбче[13] гөруһ[14] мөтәгассыйбынга[15] рәгъмән[16] синең “Баруди”ң[18+] үзенең китаплары вә мөгаллимләр җитештергән Мөхәммәдия бакчасы[19+] илә башлап милләт хезмәтенә кереште. Бу көнгәчә әдәбиятымыз эчендә мисле булмаган “Ике йөз елдан соң инкыйраз”[20+] вә иптәшләренең

---

[1]*Тәсаррыф* — идарә итү.
[2]*Дәфгыдә* — кире кайтаруда.
[3]*Һиҗрәткә* — күчеп китүгә.
[4]*Мәхкәмәгә* — судка.
[5]*Зоһур итте* — күренде.
[6]*Тәкълид* — ияру.
[7]*Зоһурилә* — килеп чыгуы белән.
[8]*Мөшәррәф булдың* — хөрмәтле булдың.
[9]*Мисле сәбкать итмәгән* — элек мисалы булмаган.
[10]*Мәзъһәр* — чыганак, җирлек.
[11]*Изһар кылдың* — күрсәттең.
[12]*Ысуле җәдидә* — яңа метод.
[13]*Тәкый гаҗәбче* – искиткеч диндар.
[14]*Гөруһ* – төркем.
[15]*Мөтәгассыйбынга* – фанатиклыкка, патриотлыкка.
[16]*Рәгъмән* – каршылык итеп.

мөхәррире зоһури шәрәфенә син ирешдең*. Милли әдәбият чишмәсе башлап синнән акты. Идел буе татарларының иң беренче гәзитәләрен башлап син яздың; үзеңне артык сөйгәнгә, ул гәзитәне үзеңә нисбәт белән «Казан мөхбире»[21+] дип атадың. Әүвәлге кыйраәтханәне син ачтың[22+]. Башлап театру синдә уйналды[23+]. Остазларының дога вә фатихаларына алданып яткан, дин вә дөньядан хәбәрсез булган шәкертләргә үз хәлләрен башлап син аңлаттың; анларга иң элек син хәрәкәт бирдең. Синең шәкертләрең уянып, иң башлап: «Әльислахе мәдарис!»[24+] — дип кычкырды вә, шул тавышка башка илләрдәге шәкертләр дә уянып, заман әхвален төшенә вә ислахате гыйльмия[1] өчен тырыша башлады. Шәкертләрнең ихтияҗатенә хезмәт өчен башлап «комитетлар» синдә ачылды, яшерен гәзитәләр синдә чыкты[25+]. Иң әүвәлге җәмгыятьләр синдә булды. Мөгаллимнәр җәмгыятене[26+] дә син үзеңдә ясадың. Милләтемез эчендә синең мәүкыйгыңны[2] шул дәрәҗә мөхтәрәм күрәмен ки, шул мәүкыйгның хөрмәте өчен мин бу урында синең кара якларыңнан бәхәс итеп, бөтен татар галәменә «фәхешханә»ләр ачу вә анларны дәвам вә тәрәккый иттерү каралыгы; башка милләтләр хөррият вә сәгадәт өчен җан фида кыйлган вакытта синең бер кыйсем голәма вә әгънияң[3]... артыннан йөргәнлеге; милләтнең иттифак вә иттихадына[4] балта чапкан «таң»чы малайларга[27+] синең вөҗүд биргәнлегең кеби чиркин[5] хәлләреңне язарга да лязем[6] күрмим. Синең бу каралыкларыңны яхшы ягың мең кәррә җиңә, шуңар күрә мин синең хакыңда: «Яшә, Казан... милләт илә бергә яшә!» — диюдән башканы белмим. Сине тарих тәкъдир итәр. Киләчәк милләт балалары сиңа рәхмәт укыр... Шәүкәтеңне теләп: Сәлим».

## III

Беркадәрле заманнар кичкәннән соң, Сәлим икенче мәртәбә дәхи Казанга килмеш иде. Фәкать бу килүендә ул инде сурәте вә фигурасы белән генә әүвәлге Сәлим булып, идея вә игътикады җәһәтеннән[7] исә бөтенләй башка кеше вә бөтенләй икенче Сәлим иде. Ул, тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният[8] даирәсенә» күчкән; милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган; «милләтем... татарым...»ны ташлап, «ватаным — бөтен

---

*Шушы ике җөмлә 1974 елда чыккан сигезтомлыкның 1нче томының 480нче битендәге шакмак җәяләр эчендәге кыскартылган өзек.

[1]*Ислахате гыйльмия* — белем бирү эшләренә реформа кертү.

[2]*Мәүкыйгыңны* — тоткан урыныңны.

[3]*Әгънияң* — байларың.

[4]*Иттифак вә иттихадына* — берләшү һәм оешуына.

[5]*Чиркин* — кызганыч.

[6]*Лязем* — кирәк, тиеш.

[7]*Игътикады җәһәтеннән* — ышануы, идеалы ягыннан.

[8]*Инсаният* — кешелек.

җир йөзе... миллэтем — бөтен бәни бәшәр[1]» нәзариясенә[2] иман китергән иде. Тәәссефемезгә каршы[3], ул бу килүендә Хан мәсҗеден зиярәт кылу вә анардан бер тәәссер алу кайда, аны бер кәррә уйламады да. Татар көтепханәләренә вә кыйраәтханәләренә кереп, гәзитә вә рисаләләр[4] карау да аның шатлыгын китермәде; билгакес[5]: «Бу татарлар тәҗвид[6] дәвереннән кайчан үтәр икән?» — дип, матбугатның бик түбәнлеге хакында борчылды.

Былтыр ләгънәт илә тәлкый ителгән[7] «таң»чылар бу ел аңарга иң хакыйкый адәмнәр булган иде; ул «Таң» вә «Тавыш»ның[28+] тукталуына ифрат кайгырып, анларның идарә урыннарын вә язучыларын эзләп җәдәп бетте. Анлар тарафыннан нәшер ителгән кечкенә брошюрларны күргән саен күңеле шатлана вә зиһененнән бер дәрт илә: «Килер бер көн: бөтен түбән сыйныфлар, үз хәлләрен аңлап, җиңелмәс куәт илә мәйданга чыгарлар... Менә бу кечкенә брошюрлар шул көннең ерак калмаганын белдерәләр», — уе кичә иде. Табигый, ул татар ханлыгының бу көнгәчә Казанда хөкем сөрмәвенә агламады; бәлки, гыйлем чишмәсе вә мәдәният терәге улан университетны, институт, гимназия, реальный вә саирә[8] бик күп монтазам[9] мәктәпләрне вә һәртөрле гыйльми вә хәери мөәссәсатны[10] күреп: «Татар ханнары хөкем сөрсә, бунларның һичбере булмас, Казан икенче Бохара булып, бунлар урынында тәкияләр[11], дәрвишханәләр вә хәрабәләр булыр иде», — дип уйлады.

Күп кешеләр аның бу үзгәрешләрен «тәкълид», «мода бәласе» вә сәбатсызлык[12] дип карасалар да, ул үзе бунда тәкълид тә, сәбатсызлык та күрми, бәлки «бик табигый булган бер инкыйлаб» дип карый иде. Аның фикеренчә, һәр кешенең даирәи мәсләге, вәсгате фикриясе илә мөтәнасиб була[13]; балалар фәкать үз гаиләләрен генә сөяләр; соңра шул тар даирә киңәя-киңәя, фамилия, кабилә, милләт, ватан даирәләреннән үтеп, инсанияткә җитәргә тиеш. Һәркемдә табигый даирә — «инсанияттер». Фәкать адәмнәрнең кабилә, милләт кебек даирәләргә тәгассыбы рух вә фикер тарлыгыннан гына килә.

---

[1]*Бәни бәшәр* — адәм балалары.
[2]*Нәзариясенә* — карашына.
[3]*Тәәссефемезгә каршы* — кызганычка каршы.
[4]*Рисаләләр* — китаплар.
[5]*Билгакес* — киресенчә.
[6]*Тәҗвид* — Коръәнне дөрес уку кагыйдәләре, бу урында «иҗек ятлау» мәгънәсендә.
[7]*Тәлкый ителгән* — танылган, кабул ителгән.
[8]*Саирә* — башка.
[9]*Монтазам* — тәртипле.
[10]*Хәери мөәссәсатны* — кешеләргә яхшылык эшләүне күздә тоткан оешмаларны.
[11]*Тәкияләр*— мөридләр җыела торган урыннар.
[12] Сәбатсызлык — фикердә тотрыксызлык.
[13]*Даирәи мәсләге, вәсгате фикриясе илә мөтәнасиб була* — дөньяга караш даирәсе фикер киңлегенә туры килә.

Гавам җаһилдер[1]. Шуңар күрә ул милләттән дә түбән, фәкать кабилә тәгассыбында кала; әһле гыйлемдә исә, киңәя-киңәя инсаниятькә җитү тиеш улан даирәне махсус тәрбия вә тәэсират илә буып, миллияттә туктаталар. Үзенең инсаниятчелеген ул шул назарияләр илә мөдафәга кыла[2] иде. Аның бу назариясенә каршы: «мәдәни милләт зыялылары милләтче бит; безгә дә анларга мокабәләте миллият[3] тиеш!» — дип игътираз кылсалар да[4], ул бу игътираза каршы: «Кеше эшли дип, ярамаган эшне эшләү үзе хәмакать[5]», — дидер иде. Нәзариясе батыйльме[6], ялганмы, аның мәсьүлияте[7] үзенә, ләкин ул шунларга таянып инсаниятче булу тиеш дип лаф ора иде. Казанга икенче килүендә аның рухи ләүхәләрендә менә шул фикерләр тәрсим иткән[8] иде.

**IV**

Менә шушы Сәлим, шушы «халык хадиме», хикәянең башында диелгәнчә, өченче кәррә дәхи Казанга килде. Бер идея белән Казанны ике кәррә күрү аңа, ахрысы, насыйп түгелдер. Бу өченче килүендә ул дәхи бөтенләй үзгәргән вә бөтенләй икенче мәсләккә кергән иде. Аның бу соңгы мәсләке, иң җыйнак тәгъбир белән әйтсәк, «ул идеясез калган, идеясезлек фикеренә бирелгән» иде.

Зур вә мөдһиш[9] бер инкыйлаб: аның әүвәлге үзгәрешләре динчелектән милләтчелеккә, милләтчелектән инсаниятчелеккә чыгу кеби, бер идеядән икенче идеягә күчүдән генә гыйбарәт булып, бәһәр тәкъдир[10] ул бер «фидаи», бер инкяреззат[11] тарафдары улан хадимелгомум[12] иде. Ул вакыт аның зиһене вә бөтен рухы фәкать «хезмәт... хезмәт» дәрте илә тулы булып, шәхси мәнафигъны[13] һичбер уйламый да иде. Үзе өчен кайгыру, үзенең генә сәгадәте өчен тырышып мал, байлык, гаилә вә гүзәл тормыш артыннан йөрүне ул бик ваклык вә пислек[14] саный, бунларга тәхкыйрь[15] күз белән карый иде. Рухы вә күңеле рәхәтлекне мосриф[16] тормыш эчендә түгел, бәлки халык өчен корбан булуда, халык хезмәтендә йөрүдә күрә вә бөтен

---

[1]*Гавам җаһилдер* — халык надандыр.
[2]*Мөдафәга кыла* — яклый.
[3]*Мокабәләте миллият* — милләтчелеккә каршы кую.
[4]*Игътираз кылсалар да* — каршы килсәләр дә.
[5]*Хәмакать* — ахмаклык.
[6]*Батыйльме* — яраксызмы.
[7]*Мәсьүлияте* — җаваплылыгы.
[8]*Тәрсим иткән* — сурәтләнгән.
[9]*Мөдһиш* — куркыныч.
[10]*Бәһәр тәкъдир* — һәрхәлдә.
[11]*Инкяреззат* — үз шәхесен түгел, җәмәгать файдасын алда тоткан кеше.
[12]*Хадимелгомум* — халык хезмәтчесе.
[13]*Шәхси мәнафигъны* — үз файдасын.
[14]*Пислек* — түбәнлек.
[15]*Тәхкыйрь* – нәфрәт.
[16]*Мосриф* — әрәм.

тәвәҗҗеһатен[1] шул ноктага җыя иде. Ул үзенең «идея»сенә корбан вә халыкка үзен фида кылган иде.

Бу соңгы килүендә исә ул бу уйлар, бу өмидләр, бу гали хыял вә идеяләрнең һәммәсеннән аерылган; тормышының каты тулкыннары эчендә анлар бар да югалып бетеп, урыннарын «мәнафигы шәхсия» фикере тәмам ишгаль кылган[2] иде.

Гомум мәнфәгатеннән башканы уйламаган димагсы[3] хәзер үзенең бөтен куәтен ялгыз «үз файдасын» уйлауга сарыф итә башлаган, аның бөтен тәвәҗҗеһате «үземнең рәхәтем» ноктасына кадалган иде. Университетка керү дәрте, аны күрү белән шулкадәр тәэсирләнүенең сәбәбе дә башка һичнәрсә өчен түгел, ялгыз истикъбальдә[4] үзенең сәгадәтен тәэмин өчен генә иде. Күптән түгел нәзаре тәхкыйрь вә алчаклык[5] белән каралган «шәхсият» хәзер аның кашында бөтен мәкасиднең[6] әүвәле вә ахыры булган иде. «Гыйлем» хәзердә аның өчен гомум мәнфәгатенә хезмәт өчен түгел, бәлки үз сәгадәтенә васита[7] өчен генә иде.

Аның хәзерге «рухани ләүхә»се менә шул иде. Үзе буны бик табигый күрә, бөтен дөнья вә бөтен тәбаигы бәшәр[8] шулай булгач, ул да шулай булырга тиеш кеби карый вә күңеле шуңардан бик риза иде. Фәкать рухының иң төбендә «мәнафигы шәхсия дәртләреннән» куркып, җиңелеп, иң тирән җиргә яшеренгән бер чаткы — бер наразыйлык[9] чаткысы бар иде; ул даимән теге фикергә җиңелсә дә, кайбер вакыт бәгъзе бер тәэсир сәбәпле азрак башын күтәреп куя; Сәлимнең гакылына мөрәҗәгать итеп: «Уйлачы, зинһар... син кем булдың?» — дип сөаль бирә иде. Идеясезлектән наразыйлык күрсәткән бу кечкенә чаткының сөале бәгъзан Сәлимнең вөҗданын шул югарыдагы сөаль белән газаплый; ләкин күп вакытта: «Кем булыйм... тормышта табигый булган бер фикергә кайттым», — җавабын ишетеп, кире егыла иде.

Казанга килеп, мондагы инсаниятче яшьләр вә милләтче картлар вә гомумән бер заманнар «гомум хәсрәтен» чиккән адәмнәрнең һәммәсендә дә «идея вә хезмәт дәрте» бик начар хәлгә төшкәнен, бик вә бик күбесе андый хыяллардан тәмам ваз кичеп, фәкать мәнафигы шәхсиягә бирелгәннәрен күргәч, ул кечкенә чаткы тагы ныграк җиңелде.

Әүвәл килүләрендә аның иптәшләре вә танышлары илә булган

---

[1]*Тәвәҗҗеһатен* — тырышлыгын.
[2]*Ишгаль кылган* — биләп алган.
[3]*Димагсы* — зиһене, фикере.
[4]*Истикъбальдә* — киләчәктә.
[5] *Алчаклык* – миһербансызлык, ярсулык,оятсызлык.
[6]*Мәкасиднең* — максатларның.
[7]*Васита* — чара.
[8]*Тәбаигы бәшәр* — кешеләрнең табигате.
[9]*Наразыйлык* — ризасызлык.

мосахәбәләре[1] һәрвакыт «гомум» тугрысында булса да, инде бу юлы аны авызга да алмый башладылар; күп вакыт ул идеяләрдән көлеп: «Бар иде соң безнең дә шәкертлек, хыялчылык заманнары», — дип тәгъбир итәләр иде. Яшьләр эченнән бу «көлүне» бик ифратка җибәргәннәре, «идея» вә хезмәткә тәхкыйрь белән караганнары да күп очрады. Сәлим белән анлар бу инкыйлабта бер вә шәрик[2] иделәр. Менә шул иде Сәлим.

**V**

Сәлимнең Казанга килүенең өченче көне иде. Иптәшләре илә утырышып, шул «хыялчылык дәверләре» хакында төрлечә көлешеп, яңа гына номерына кайткан иде. Теге, керле алъяпкычлы плавой аңа бер мәктүб кертеп бирде:

«Газизем Сәлим!

Синең Казанга килүеңне вә адресыңны Садыйк аркылы белеп, күрешер өчен номерга барган идем. Мәгаттәәссеф, өйдә тугры китерә алмадым. Әгәр дә вакытыңыз булса, бу көн кич сәгать җидедә минем фатирыма рәхим итәсез...

*Җәлил. Сәнә һәм ай ... Адресым...*»

Шул мәктүбне калдырган Җәлил әфәнде Сәлимнең якын белешләреннән вә беркадәр мәгыйши мәсьәләләрдә[3] дә багланган кешеләреннән иде. Ул үзе Казанныкы булса да, монда күп тормый; әле дә вакытлы бер эш белә генә килгән иде. Сәлим аны фазыл вә кәмале[4] өчен сөя вә ихтирам кыла иде.

Мәктүбне уку белән борынгы бер белеш әфәнденең мөлякат ителәчәге[5] аңар бертөрле күңеллелек бирде. Барырга вакыт җиткән иде, кичкә иптәшләрдән берәрсе килер дип уйлап, бүлмәсен җыештырды да барырга чыкты. Җәлилнең әле һаман борынгы «идея»дә булганын Сәлим ишеткән иде. Аның белән бер моназәрә[6] чыгуын ихтималлап, юлга юнәлде. Бу барганда Җәлил өйдә иде. Садә вә пөхтә бер бүлмәгә керде. Җәлил, бик эчке шатлык белән каршы алып, кулын кат-кат кысып күреште. Чәйсез... «әңгәмә» кызмас дип, чәй әйттерделәр. Беркадәрле заманнар мәсләк вә мәкъсадта шәрик улан вә беркадәр хезмәтләрдә дә кушылган ике мөхибнең[7] сүзләре, табигый, бик килеште. Сүз бере-берен тартып, бик күп мәсьәлә сөйләнде. Башта, аерылганнан бирле үткәргән хәятларының тарихы вә мөһим вакыйгаләр хакында сөйләшеп, ләззәтле бер мосахәбә тәшкил иттеләр.

---

[1]*Мосахәбәләре* — сөйләшеп утырулары.
[2]*Шәрик* — иптәш.
[3]*Мәгыйши мәсьәләләрдә* — тормыш-көнкүреш мәсьәләләрендә.
[4]*Фазыл вә кәмале* — намуслыгы һәм җитдилеге.
[5]*Мөлякат ителәчәге* — очрашачагы.
[6]*Моназәрә* — бәхәс.
[7]*Мөхибнең* — дусның.

Җәлилдә «идея» әсәре көчле иде. Халык кайгысына гаид[1] ләүхәләрне тасвир вакытында ул йә шатлык вә йә кайгы изһар кыла; Сәлим исә һичбер тәэсирсез әллә нинди фаҗигаләрне сөйли иде.

Озак заман дәвам иткән мосахабәнең соңгы очы хезмәт, идея вә халык кайгысына барып кагылды. Идея хакында тугрыдан-тугры сүз ачылганчук та анлар берсенең борынгы идея булып, икенчесенең аннан ваз кичкән икәнчелекне аңлашканнар иде.

Җәлил, эчендәге тәэссефен[2] яшерү өчен, үзенә елмаю сыйфаты биреп, мәсьәләне ачты:

— Иптәш, мин яшьләрдә вә гомумән аңлы адәмнәремездә Идеянең бик начар вә түбән хәлгә төшкәнен күрәм... Сез дә шулаймы?

Бу таякның бер башы үзенә кагылганын ачык белсә дә, Сәлим үзендә һич уңайсызлык сизмәде. Билгакес, бу мәсьәлә чыккандагы була торган истихфафән[3] көлеп җибәрү гадәтен көч белән басып, болай диде:

— Мин дә шулай күрәм: күптән түгел үзләрен гомум хезмәтенә корбан кыйлырга хәзер булган әфәнделәр бу көндә гомум өчен кыл да кыймылдатасылары килми, хәзер һәркем үзе вә мәхыз[4] үз рәхәтен генә уйлый башлады.

— Тәэссеф, иптәш, бик зур тәэссеф. Халкымыз эчендә саннары бик аз булган зыялылар, хосусән истикъбальнең бөтен өмиде үзләренә багланган яшьләрнең шундый бер фахиш юлга бирелүләре өчен никадәр тәэссеф вә тәгаҗҗеб итсәк[5] тә аздыр. Мин бу мәсьәләнең вә бу хәерсез инкыйлабның серен белә алмыйм.

Бу сүзләргә Сәлим эчтән көлсә дә, Җәлил хәтере өчен җитди вә әдәби бер моназәрә рәвешендә алып барырга карар биреп, болай диде:

— Ләкин мин бонда бер сере мәгълүм булмаган нәрсә күрмим. Минемчә, бу бик гади вә табигый булган бер хәлдер.

Җәлил ашыга төшеп аның сүзен кисте:

— Ничек бик гади вә бик табигый дисез?.. Әллә сезнеңчә шулай булу тиешме?

— Тиешме, түгелме — анысы икенче мәсьәлә. Ләкин ул шулай була... Шулай булмый кала алмый... дип беләм. Чөнки инсанның табигате вә каны гомергә идея капчыгы булып, үзенең бөтен рәхәтеннән ваз кичүне тәхәммел итә алмый[6]. Әллә сез шул вакытлы гына кузгалган хисләрнең мәңге булуын

---

[1]*Гаид* — кагылышлы, бәйләнешле.
[2]*Тәэссефен* — борчылуын.
[3]*Истихфафән* — мыскыллы.
[4]*Мәхыз* — фәкать.
[5]*Тәгаҗҗеб итсәк*— гаҗәпләнсәк.
[6]*Тәхәммел итә алмый* – күтәрә алмый.

көткән идеңезме? Әллә, шул бишенче-алтынчы еллардагы кебек, һәркем гомер буена гомум кайгысын кайгыртып, үз мәнафигыннан ваз кичәр дип уйлаган идеңезме? Бу һичбер вакыт мөмкин түгел.

— Юк, мин алай үз сәгадәтләреннән бөтенләй ваз кичсеннәр димим; кичсәләр бик яхшы, бик зур кәмаль. Ләкин кичмәгән тәкъдирдә дә, үзеңне генә уйлап, гомум мәсьәләсеннән бөтенләй ваз кичәргә ярамый иде. Һич булмаса, тигез алып бару кирәк иде.

— Дөрест, ул шулай тиештер. Ләкин мәгыйшәт кешене кыса; сезнең ул фәлсәфәләреңезне бер якка атып бәрә. Инсан ихтыярсыз ялгыз үз хәсрәтен чигәргә, үзен генә кайгыртып, башкаларны онытырга мәҗбүр була. Бу табигыйдер. Гомум бәшәрне җиңгән шул табигый куәт әлбәттә безне дә җиңде; күптән түгел фидаи булып йөргән адәмнәр хәзер шул «үзем» тәртәсенә җигелделәр вә гомергә шуны өстерәячәкләр.

Бу сүзләр Җәлилнең рухын бик тулкынлаткан вә аңарга гасабият биргән[1] иде. Артык сүз ычкындырмас өчен, мәсьәләне азрак кисеп, Сәлимнең чынаягына чәй ясады; өстәлне ипләде, соңра диде:

— Нинди ят мөгаләталар белән әдилләләр[2] тәртип кылсаңыз да, мин сезнең бу дәгъваңызга ышана алмыйм. Чөнки: үзен вә бөтен сәгадәтен гомум фаидәсенә корбан кылган вә бөтен гомерләре буенча халык хезмәтендә йөргән адәмнәрнең барлыгы сезгә мәгълүм бит... Без дә шуларның берсе булсак ярамасмы?

— Бик ярар иде; ләкин сез әйткән адәмнәр дөньяда бар микән соң? Мин моңа ышанмыйм. Анларның гомер буенча милләт вә халык өчен яки башкача бер гомум хезмәт өчен йөрүләре «идея»дән түгел, бәлки шәхси мәнафигъларын тәэмин өчен бер васита булганлыктан гынадыр. Анларны идея түгел, бәлки мәнафигы шәхсия хезмәт иттерә. Анлар садә әһалине[3] имү өчен генә хезмәтләренә «гомуми идея» буявы бирәләр. Хасил: мин кешенең гомум мәнафигы вә һичбер җәһәттән үзенә фаидә килмәгән бер мәкъсад өчен хезмәт итүенә ышанмыйм. Кеше үзе өчен генә тырыша. Һәркем... һәркем шулай.

Җәлил буңа көлде. Галәбәне үз тарафына борырга юл ачылганын ифадә тарз илә[4] диде:

— Сез бераз яңлыштыңыз бугай. Ничек «гомумгә хезмәт» идеясен көллән[5] инкяр итәсез; сез бит үзеңез дә күптән түгел бер хадим, бер фидаи идеңез...

---

[1]*Гасабият биргән* — нервларын кузгаткан.
[2]*Мөгаләталар белән әдилләләр* — ялгыштыру, хатага этәрү белән дәлилләр.
[3]*Садә әһалине* — гади халыкны.
[4]*Ифадә тарз илә* — аңлату юлы белән.
[5]*Көллән* — бөтенләй.

— Дөрес, миндә дә шундый хыялый чаклар бар иде. Һәм минем белән бергә башка бик күп кешеләр дә шул фикердә иде. Ләкин бу вакытлы искән бер җилдер. Исте дә кичте. Табигать аны күтәрә алмады. Мин хәзер ул Сәлим түгеллегемне игътираф итәм[1]; ә кайсы кешеләр, үзләре икърар итсәләр дә, гомумгә һаман борынгы буяуда күренәләр. Чөнки: яшәргә кирәк... корсак галәйһессәлам шулай куша.

— Димәк, сез хәзер гомумгә хезмәт уеннан бөтенләй ваз кичтеңез. Ул идея сездә калмады?

Бу сөальгә җавап бирү хакында аның вөҗданы бераз газапланды. Теге наразыйлык чаткысы аглады.

— Сез бик авыр сөаль бирдеңез... Бу миңа начар тәэсир итеп, үземнең хәзерге фикеремне чиркин күрсәтте. Ләкин шунда да игътираф кылам: бөтен адәмнәрне кыскан мәгыйшәт мине дә кысты; гомуми идеяләрдән аерып, фәкать үземне кайгырта вә үзем өчен тырыша торган ясады. Теләп түгел, бәлки ихтыярсыз мин шул юлга бирелдем.

— Тәэссеф, иптәш, бик зур тәэссеф. Әгәр дә сез гомергә шул мәкъсадта калсаңыз, гади бер интеллигенттан башка һичкем була алмассыз. Ышанам, дарелфөнүнне[2] дә бетерерсез; ләкин, мәкъсадыңыз корсак булганга, шуннан башканы таба алмассыз. Якын күргәнгә бу рәвешле сөйлим... Тәгъбиратны гафу идеңез..:

— Зарар юк. Мин үзем дә тәкәллефсез вә ачык тәгъбирне яратам.

Җәлил дәвам итте:

— Кеше ни нәрсә эзләсә, шуны таба. Бөтен тәвәҗҗеһаты үз мәкасадына гаид инсан[3] бер вакытта да «мәшһүр бөек адәмнәр»[29+] рәтенә тезелә алмый.

Сәлимгә бунлардан кечек бер тәэсир җыелды. Ул, әүвәлге кеби эчтән көлеп түгел, бәлки җитди иһтимам[4] белән сөйләшә башлады. Ләкин әле ул канәгатьсез иде.

— Җәлил әфәнде, сез идея-идея диясез... ләкин минем сөалемә җавап бирмисез... Бөтен дөнья вә бөтен адәмнәр шулай бит... Дөньяда һичкем үзеннән башканы кайгыртмый... Бу табигать бит... Буңа сез ни дисез?

— Мин буңа кыйсмән иштирәк итәм[5]. Адәмнәрнең бик азын истисна кылсак[6], калганнары һәммәсе дә фәкать үзләрен генә, үз рәхәтләрен генә уйлыйлар, вә шуңа гына тырышалар, һәм гомумгә хезмәт итәмез дигән

---

[1]*Игътираф итәм* — таныйм.
[2]*Дарелфөнүнне*— югары уку йортын, университетны.
[3]*Гаид инсан* — бәйләнешле кеше.
[4]*Иһтимам* — кызыксыну.
[5]*Кыйсмән иштирәк итәм* — өлешчә кушылам.
[6]*Истисна кылсак*— аерып алсак, чыгарма ясасак.

адәмнәрнең дә иң күбе риядан гына, үз мәнафигына васита өчен генә шулай кычкыра. Ләкин бунлар гади адәмнәрдер. Дөньяда дәхи шундый гали табигатьле вә бөек рухлы адәмнәр бар: анлар үзләре өчен генә кайгыруны пислек вә хайванлык саныйлар; үзләрен гомум өчен фида кылалар. Тарихта бөеклек вә ихтирам илән урын алган әрбабе кәмаль һәммәсе[1] дә менә шул нәугы[2] инсаннардыр. Теге гади инсаннар бу идеяне, әлбәттә, күтәрә алмый, анларга бундый бер мәсләк керсә дә, тиз чыга. Анларның гади рухлары үз мәнафигъләреннән башканы кайгыртырга сәлахиятле[3] түгел. Аңлата аламмы, юкмы? Минем идея вә гомумгә хәйер хаһлык[4] тугрысында бөтен уем менә шул: идеясезлек — бик түбәнлек вә хайванлыктыр. Идея — фәкать гали рухларда гына мәңге яши. Кем үзендә идея хис кылмаса, ул адәм үзенең йә бозылганлыгына яки түбән рухлылыгына ышансын. Гомумгә хезмәттән ваз кичеп, идеясезлекне игътираф — үзеңнең бөек бер фазыйләткә әһел[5] булмаганлыгыңны, түбәнлегеңне икърардыр. Башка сәбәпләр илә бәрабәр идея инсанның иң бөек мәуҗибе тәрәккыйсе[6] кәмаләтене фагыйльдер[7]. Кеше шуның аркасында кәмаль вә фазыйләткә ирешә. Шуның сәукы илә[8] хезмәткә тотынып, тарихта нам вә ихтирам казана. Ансыз нә нам[9], нә ихтирам...

Җәлил, бу мәсьәләне үзенчә бик мөһим күргәнгә, гадәттән артык сөйләде, Сәлимнең тыңлаудан ялыгуына дикъкать итмичә, үзенең сүзен дәвам иттерде:

— Идеяне тәгъйин[10] мәсьәләсе, минемчә, икенче дәрәҗәдәдер. Аны кеше үзенең табигать вә рухының сәукы илә интихаб итә[11]: милләт тәрәккыйсенә хезмәт... тырышу, хатыннарның азатлыгы вә мөсавәте[12] мәсьәләсенә, яки гыйлем вә мәдәниятнең тәрәккыйсенә, яки үзеңчә чын дип ышанган... вә саир... вә саир... кеби гомуми идеяләрдән берен интихаб илә шуңа тырышу — иштә[13] инсанга лаек улан бер кәмальдер. Бу кәмаль сахибенә икенче кәмаләтне тугдырадыр. Үзен генә кайгыртып, үз рәхәте өчен генә тырышкан адәм, идея җәһәтеннән, үз корсагы тулгач һичкем өчен гамь чикми торган ялкау ишәккә бик охшыйдыр.

Бу мосахәбәләр берничә кәррә тәкрар итте. Җәлил Сәлимне бер

---

[1] *Әрбабе кәмаль* — олы җанлы кешеләр.
[2] *Нәугы*— төре.
[3] *Сәлахиятле* — сәләтле.
[4] *Хәйер хаһлык* — изгелек, яхшылык теләү.
[5] *Фазыйләткә әһел* — күркәм сыйфатка ия.
[6] *Мәуҗибе тәрәккыйсе* — алга җибәрүчесе.
[7] *Кәмаләтене фагыйльдер* — камиллеккә илтүче.
[8] *Сәукы илә* — әйдәве белән.
[9] *Нам* — шөһрәт, исем.
[10] *Тәгъйин* — билгеләү.
[11] *Интихаб итә* — сайлап ала.
[12] *Мөсавәте* — хокукта тигезлек.
[13] *Иштә* — чынында.

«идея»ле кеше ясый алмаса да, ул фәкать үзең өчен генә тырышу фикереннән бер төрле нәфрәтләнә, аны бик ваклык күрә башлады. Рухының төбендәге наразыйлык чаткысы куәт алып, аны шул тугрыда уйларга, вөжданын вә рухын газапларга башлады. Аның табган голүвиятә мәйяль[1] улан рухы вә күңеле ул «үзем» ноктасына гына кадалып калуга канәгатьсезләнде.

**VI**

Казанның һәммә урамнары тынган иде. Бөтен адәмнәр илә бәрабәр трамвай да, «барабыз»лар[2] да йоклаган, кич үзенең калын караңгылыгы эченә бөтен нәрсәне алып, һәр җирдә мәвет вә сөкүнәт[3] хөкем сөрә башлаган иде.

Кяинатнең[4] шул тын вә йокылы чагында Сәлим акрын вә салмак атлап Җәлилнең фатирыннан чыкты. Ул да дүртенче кәррә уларак Җәлилгә килгән, вә һәр килүендә башка мәсьәләләр илә әүвәлге мәҗлестә кузгалган идея мәсьәләсен дә чәйнәгәннәр иде. Бу мөсахәбәләр Сәлимдә байтак тәэсират кузгатып, аны тирән уйларга чумдырган иде.

Ул кайткан вакытта номер ишекләре бикләнгән иде. Швейцар саңгырау вә аңлашылмый торган сүзләре белән сукранып аны кертте. Бөтен номерда шылт иткән тавыш юк; тирән бер тынлык дәвам итә иде. Ул номерын ачып керде дә башка һичнәрсәгә кул салмыйча вә киемен дә чишенмичә урындыкта утырды. Бераз тәфәккердән соң[5] чишенеп ятты. Ләкин никадәрле көчләнсә дә, йоклый алмады, аның фәгъгаль димагысы[6] җитди тәфәккерат илә мәшгуль булганга, күзләреннән йокы очкан иде. Зиһененә төрле уйлар, хыяллар вә мазый-истикъбальдән[7] төрле ләүхәләр килде. Үзенең ике дәвердәге хәятын тәфсилаты белән тәдкыйк кылганнан соң[8], ул тәмсез вә ачы нәтиҗәләр күрде: ул халыкка хезмәт идеясе белән йөргән вакытларда вөҗданлы вә һәркемгә хәйер хаһлы иде. Күңеле гали өмидләр вә изге ниятләр белән тулы иде. Һәрвакыт фазыл вә кәмаль ягына мәел итә, кешеләргә яхшылык итәсе килә; бөтен вөҗүде икенчеләргә мөмкин кадәрле фаидә итү теләге белән тулган иде. Кайчан идеяләреннән аерылып, фәкать үз мәнфәгать вә үз рәхәтләрен генә уйлый башлады исә, шул вакыттан башлап аның рух вә вөҗданы тәнәззел итте[9]. Андагы изге ниятләр, фазыл вә кәмальгә мәелләр берәм-берәм түгелеп, хайвания галәбә кылды[10]. Рух вә димаг үзләренең

---

[1]*Табган голүвиятә мәйяль* — табигате белән югарылыкка омтылучы.
[2] *«Барабыз»* – шәһәр урамында кеше ташый торган чана, арба.
[3]*Мәвет вә сөкүнәт* — үлем тынлыгы һәм хәрәкәтсезлек.
[4]*Кяинатнең* — бөтен дөньяның.
[5]*Тәфәккердән соң* — уйланудан соң.
[6]*Фәгъгаль димагысы* — эшчән мие, зиһене.
[7]*Мазый-истикъбальдән* — узган һәм киләчәктән.
[8]*Тәфсилаты белән тәдкыйк кылганнан соң* — бөтен ваклыклары белән тикшергәннән соң.
[9]*Тәнәззел итте* — түбәнәйде.
[10] *Галәбә кылды* – җиңде.

тәвәҗҗеһатен[1] алыштырып, бик вак нәрсәләр белән генә мәшгуль була башладылар. Һәр шәй[2] алышынды. Һәрбер сафвәт[3], кәмаләт вә голүвият югалып, фәкать «үземә рәхәт булгач... кеше өчен ник кайгырыйм... кеше өчен нигә үземне борчыйм...» гыйбарәсе илә тәгъбир кыла торган бер «мәнфәгате шәхсия вә рахәте шәхсия» дәрте генә калды.

Менә үзенең ике дәвердәге «рухани ләүхәсен» тәдкыйк иткәч, шундый күңелсез нәрсә күрде. Бу соңгы ләүхә аның нәфрәтен иҗаб итте[4]. Ул үз-үзеннән бизеп, теге наразыйлык чаткысы тәмам кузгалды. Идеяле дәвере вә андагы мәкасыйде[5], гүзәл вә сөемле бер фәрештә кебек, аның мәхәббәтен җәлеп кылды. Соңгысы исә, мөҗәссәм бер иблис кеби кабих күренеп, аны җирәндерде. Аның рухы әүвәлге мәсләк заманын сагына вә шуның кире кайтуын тели башлады. Шул дәвергә, шул идеягә кайтса, бер бөек дәрәҗәгә ирешкәндәй булыр кеби иде.

Дөньяның бөек адәмнәре, анларның кылган бөек хезмәтләре вә фидаилыклары үзләренең идеяләре өчен корбан булулары вә саир уйлар кичте. Шунлар кеби булмак, рәхәт вә сәгадәтне шул гомумгә хезмәт эчендә эзләмәк аның да бер вакытлы мәкъсадлары иде. Әгәр да шул мәкъсад белән барса, шул бөекләрнең сыйныфына керер кеби тоелды.

Үзен-үзе ислах итеп, рухын хәзерге вак вә чиркин мәкъсадлардан пакьли алса, әүвәлге шикелле мөкаддәс мәсләк өчен хезмәт итүгә бирелсә, зур сәгадәткә ирешкән булыр иде кеби хис кылды.

Бу вакыт күк йөзе ачылып, айның тоныкъ нуры аның тәрәзәсенә төшеп, үзене җәлеп итте; ул торып айга карады. Күгелҗем вә на мөтәнаһи фәза[6] эчендә йөзеп йөргән мәһабәт ай аңар бертөрле голүвият салды. Уйлары дәхи тирәнгә китеп, хисләре нечкәрде. Тирән бер тын алып, бик эчтән сөйгән бер мәхбүбене[7] сагынган кеше кеби, бер өмид вә бер тәәссеф илә ихтыярсыз авызыннан шул сүзләр чыкты:

— Кайчан мин хәзерге былчырак мәкъсадлардан пакьләнеп, әүвәлге идеяләрем, гали мәкъсадларым вә мәелләрем үземә кайтыр; кайчан мин үземне ислах вә тәрбия итеп, ул ноктага җиткеререм; шул заман минем гомердә иң мөһим период булыр. Вә шул көн минем өчен мөкаддәс бәйрәм булыр.

---

[1] *Тәвәҗҗеһатен* — юнәлешен.
[2] *Шәй* — нәрсә, әйбер.
[3] *Сафвәт* — сафлык.
[4] *Иҗаб итте* — тудырды.
[5] *Мәкасыйде* — максатлары.
[6] *На мөтәнаһи фәза* — чиксез бушлык.
[7] *Мәхбүбене* — якын дустын.